СОВЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

«11» 12. 2025 ел Алабуга шәһәре № 24

«Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнар җыеннарын билгеләү һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 22 статьясы нигезендә, Алабуга шәһәр прокуратурасының протестын караганнан соң,, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советы

**КАБУЛ ИТТЕ:**

1. «Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнар җыеннарын билгеләү һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәне расларга.
2. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнар җыеннары һәм конференцияләр үткәрүне билгеләү һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының 2007 елның 2 ноябрендәге 135 номерлы карары;

«Татарстан Республикасы «Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнар җыеннары һәм конференцияләр үткәрүне билгеләү һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 2007 елның 26 февралендәге 135 номерлы Алабуга муниципаль районы Советының карарына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 26 февралендәге 266 номерлы карары:

«Татарстан Республикасы «Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнар җыеннары һәм конференцияләр үткәрүне билгеләү һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 2007 елның 26 февралендәге 135 номерлы Алабуга муниципаль районы Советының карарына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 22 октябрендәге 409 номерлы карары.

3. Әлеге карар дәүләт теркәвеннән соң рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны муниципаль корылыш һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Рәис урынбасары А.В. Косов

Алабуга муниципаль
районы Советының 11.12.
2025 елдагы “24” номерлы
карарына кушымта

**«Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнар җыеннарын билгеләү һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмә**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Конституциясе, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 22 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы нигезендә, Татарстан Республикасы «Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставында Татарстан Республикасы «Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнар җыеннарын билгеләү һәм үткәрү тәртибен (алга таба - Район) билгели.

1.2. Гражданнар җыеннары үткәрелергә мөмкин:

1) халыкның тормыш эшчәнлеген турыдан-туры тәэмин итү мәсьәләләрен тикшерү буенча;

2) җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарә вазифаи затлары эшчәнлеге турында халыкны мәгълүмат белән тәэмин итү буенча;

3) район территориясендә яки аның бер өлешендә инициатив проектны хуплау турында гражданнар фикерен ачыклау мәсьәләсе буенча;

4) авыл торак пунктында авыл торак пункты старостасы кандидатурасын күрсәтү мәсьәләсе буенча, шулай ук авыл торак пункты старостасы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату мәсьәләсе буенча;

5) район территориясенең бер өлешендә территориаль җәмәгать үзидарәсен гамәлгә ашыру максатларында.

1.3. Гражданнар җыены халык, район Советы, район Башлыгы инициативасы буенча, шулай ук территориаль җәмәгать үзидарәсе уставында каралган очракларда үткәрелә.

1.4. Район яки район Башлыгы инициативасы буенча үткәрелә торган гражданнар җыены район Советы яки район Башлыгы тарафыннан билгеләнә.

1.5. Халык инициативасы буенча үткәрелә торган гражданнар җыены район Советының норматив хокукый акты белән билгеләнгән тәртиптә билгеләнә.

1.6. Инициатив проектны хуплау турында гражданнарның фикерен ачыклау мәсьәләсе буенча район территориясендә яисә аның территориясенең бер өлешендә үткәрелә торган гражданнар җыенында тиешле территориядә унсигез яшькә җиткән кешеләр катнашырга хокуклы.

1.7. Гражданнар җыены бәямәләре рәсми рәвештә халыкка игълан ителергә тиеш.

1.8. Гражданнар җыенын оештыру һәм үткәрү район Советы, район Башлыгы инициативасы белән җирле бюджет акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.

Территориаль иҗтимагый үзидарәне гамәлгә ашыру максатыннан гражданнарның җыелышын билгеләү һәм үткәрү тәртибе территориаль иҗтимагый үзидарә уставы белән билгеләнә.

## 2. Гражданнар җыенын үткәрүнең гомуми принциплары

2.1. Гражданнар җыенда турыдан-туры, тигез шартларда катнашалар.

2.2. Җыенда катнашу ирекле һәм ихтыяри. Гражданнарны җыенда катнашырга яисә катнашмаска беркем дә мәҗбүри йогынты ясарга хокуклары юк.

2.3. Җыен вакытында берәү дә үз фикерләрен һәм инануларын белдерергә яки алардан баш тартырга мәҗбүр ителә алмый.

2.4. Җыенны әзерләү һәм үткору ачыктан-ачык һәм хәбәрдар алып барыла.

## 3. Халык инициативасы буенча гражданнар җыенын билгеләү

3.1. Халык инициативасы белән үткәрелә торган гражданнар җыены тиешле территориядә яшәүче һәм җыенда катнашырга хокуклы халык санының кимендә 10% тәшкил иткән гражданнар төркеменең, шул территорияләрдә урнашкан предприятие, оешма һәм учреждение җитәкчеләренең язма тәкъдиме буенча район Советы тарафыннан билгеләнә.

3.2. Гражданнар җыенын үткәрү тәкъдиме түбәндәгеләрне үз эченә алырга тиеш:

фикер алышуга тәкъдим ителә торган мәсьәләнең формулировкасы;

әлеге мәсьәлә буенча җыен үткәрүнең кирәклеген һәм максатын дәлилләүне үз эченә алган аңлатма язуы;

финанс-икътисади нигезләү (җыенга җирле әһәмияттәге мәсьәлә чыгарылган очракта, аны гамәлгә ашыру җирле бюджет керемнәрен киметүгә яисә чыгымнарын арттыруга йә муниципаль мөлкәтне читләштерүгә китерәчәк яисә китерергә мөмкин);

тәкъдим ителгән вакытлар, гражданнар җыены үткәрү урыны һәм катнашучылар составы;

җыен бәяләмәре буенча йомгаклау документлары проекты.

Тәкъдимгә вәкаләтле затлар, ә җыен үткәрү инициативасы белән гражданнар төркеме мөрәҗәгать итсә, һәркайсының фамилиясен, исемен, атасының исемен, туу датасын, яшәү урыннарының адресын күрсәтеп, әлеге гражданнар имза салырга тиеш.

3.3. Район Советы үзенең алдагы (тиздән үткәрәсе) утырышында җыен үткәрү турында кертелгән тәкъдимне карый.

Тәкъдимне карау нәтиҗәләре буенча район Советы җыен үткәрүне билгели яки аны үткәрүдән баш тарта.

Җыен үткәрү турындагы тәкъдим һәм гражданнар җыенын үткәрү максаты Россия Федерациясе законнарына, Татарстан Республикасы законнарына, Алабуга муниципаль районы Уставына һәм әлеге Нигезләмәгә туры килмәгән очракта район Советы җыен үткәрүдән баш тарта.

3.4. Җыен үткәрүдән баш тарткан очракта, дәлилле язма җавап бирелә. Әлеге карарга кызыксынучы затлар тарафыннан суд тәртибендә шикаять бирелергә мөмкин.

3.5. Район Советының гражданнар җыенын үткәрүдән аның максатка ярашлы булмавы сәбәпләре буенча баш тартырга хокуклы юк.

## 4. Гражданнар җыенын билгеләү турындагы карар

4.1. Гражданнар җыенын билгеләү турындагы карар район Советы яки район Башлыгы тарафыннан кабул ителә.

Гражданнар җыенын билгеләү турында карарда түбәндәгнләр билгеләнә:
җыен үткәрү көне, урыны һәм вакыты;
җыен каравына чыгарылган сораулар;
гражданнар җыены үткәрелә торган территория чикләре;
җыен инициаторлары турында мәгълүмат һәм башкалар.

4.2. Муниципаль берәмлекнең тиешле территориясендә яшәүчеләргә җыен үткәрү вакыты, урыны, фикер алышуга кертелә торган мәсьәләләр турында алар үткәрелергә 7 көннән дә соңга калмыйча хәбәр ителә.

## 5. Халык җыенын үткәрүгә әзерлекне оештыру

5.1. Район Советы яки район Башлыгы җыелышны әзерләү һәм үткәрүне Алабуга муниципаль районының Башкарма комитетына йөкли.

5.2. Җыенда, конференциядә катнашучыларның башлангыч составы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан билгеләнә.

Җыелышта катнашучылар составына, алда торган фикер алышу темасына карап, түбәндәгеләр кертелергә мөмкин:

район территориясендә эшләүче җәмәгать оешма, партия, һөнәри союз вәкилләре;
тиешле территориядә урнашкан предприятие, учреждение һәм оешма вәкилләре;
территориаль иҗтимагый үзидарә органнары вәкилләре;
кызыксынган гражданнар;
халык инициативасы буенча җыелыш үткәрелгән очракта-вәкаләтле затлар.

5.4. Җыенга чакырылган затларга чара үткәрү датасына җиде көн кала рәсми хәбәрнамәләр җибәрелә, алар нигезендә алар җыелышта катнашу хокукына ия булалар.

5.5. Җыенда катнашучылар фикер алышуга чыгарыла торган мәсьәләләргә кагылышлы үзләренең язма тәкъдимнәрен аларны җыелыш беркетмәсенә кертү өчен чара уздыру датасына кадәр ике эш көне кала тапшырырга хокуклы. Бу очракта аларны кабул итүче органга тәкъдимнәр кергән көн кабул итү датасы булып тора.

## 6. Җыен үткәрү тәртибе

6.1. Җыен башланыр алдыннан оештыручы җыелышка килгән җыелышта катнашучыларны билгели.

6.2. Җыенда рәис булып район Башлыгы, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, район Башлыгы урынбасары яки район Башлыгы тарафыннан вәкаләтле затлар булырга мөмкин.

6.3. Рәис җыенны ача һәм каралачак мәсьәләнең исемен игълан итә, аның концепциясен, инициаторын һәм җыелыш үткәрү регламентын аңлата, җыелышта катнашучылар турында мәгълүмат бирә.

Җыен беркетмәсен алып бару өчен катнашучылар арасыннан җыелышның секретаре сайлана.

Рәис җыен эшен көн тәртибе буенча алып бара, карала торган мәсьәләләр буенча чыгыш ясау өчен сүз бирә һәм аларны тикшерү тәртибен күзәтә.

6.4. Җыенга мәгълүмати материаллар, җыен нәтиҗәләре буенча кабул ителергә тиешле карарлар һәм башка документлар проектлары Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан, Халык инициативасы буенча җыен үткәрелгән очракта - халыкның инициатив төркеме тарафыннан әзерләнә.

10. Җыенны үткәрү процедурасы беркетмәдә чагыла, ул җыен секретаре тарафыннан ирекле язма рәвештә алып барыла һәм җыен рәисе һәм секретаре тарафыннан имзалана.

Җыен беркетмәсендә фикер алышына торган һәр мәсьәлә буенча җыенда катнашучыларның чыгышларының асылы һәм фикерләре мәҗбүри рәвештә чагылдырылырга тиеш.

6.6. Әгәр җыенда катнашырга хокуклы гражданнар санының кимендә 1/3 өлеше катнашса, гражданнар җыены тулы хокуклы дип санала.

## 7. Гражданнар җыены карарлары

7.1. Җыен нәтиҗәләре (бәяләмәләре) буенча тиешле карар кабул ителә. Җыелыш карары җыелышта катнашучы гражданнарның күпчелеге тавышы белән кабул ителә.

7.2. Гражданнар җыены җирле үзидарә органнарына һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затларына мөрәҗәгатьләр кабул итәргә, шулай ук җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары белән үзара мөнәсәбәтләрдә гражданнар җыелышын тәкъдим итәргә вәкаләтле затларны сайларга мөмкин.

7.3. Гражданнар җыены кабул иткән мөрәҗәгатьләр мөрәҗәгатьләрдәге мәсьәләләрне хәл итү компетенцияләренә кертелгән җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары тарафыннан гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм вакытларда язма җавап җибәреп, мәҗбүри каралырга тиеш.

7.4. Гражданнар җыены карарын тәкъдим итү характерына ия.